Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

12 октябрь, 2022 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябредәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы (2021 елның 13 декабрендәге 32 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Пимәр авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Пимәр авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Пимәр авылында. Гражданнар җыенын 2022 елның 26 октябрьдә 9.00 сәгатьтә Совет урамы, 25А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2023 елда Пимәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрне, көндезге уку формасы студентларын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарын төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Юныс авылында. 2022 елның 26 октябрьдә 11.00 сәгатьтә Комсомол урамы буенча 14 номерлы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2023 елда Юныс торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарын төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Пимәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов